**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2011 елның 03 августындагы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2022 елның«02»декабре

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Советы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2022 елның 31октябрендәге 39 номерлы Лаеш шәһәре Советы карары белән билгеләнде.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2022елның 31 октябрендәге 39 номерлы генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турындагы карар «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2022 елның 2 ноябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында

Халык алдында тыңлаулар «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең бөтен территориясенә карата үткәрелде.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларда катнашучылар булып - муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче гражданнар, шушы территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокукка ия булучылары, шулай ук капиталь төзелешнең күрсәтелгән объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре санала.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар

җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 520/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык

тыңлаулар башлану турында 2022 елның 1 ноябрендәге 520/исх номерлы хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;

2. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;

3. 2022 елның 2 ноябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. 2022 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Арефьев Виктор Александрович – Лаеш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе;

Ачык тыңлаулар секретаре: Спиридонова Наталья Юрьевна - Лаеш шәһәре Советының баш белгече.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2022 елның 2 ноябреннән 2022 елның 2 декабренә кадәр проект экспозициясен уздыру барышында, шулай ук ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында кабул ителде.

Ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары 2022 елның 25 ноябрендә 11:00 һәм 14:00 сәгатьләрдә үткәрелде.

Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсалов катнашты.

Ачык тыңлауларда теркәлгән катнашучылар саны: 7 кеше.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче затлардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булмады.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре:

1. Ачык тыңлаулар үткән дип таныргa;
2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекынт, 2022 елның 1 декабрендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен, шулай ук әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына, карап тикшерү һәм ахыргы карарны кабул итү

рекомендациясе белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитетына ачык тыңлаулар беркетмәсенең оригиналларын һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне саклауны, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә Ачык тыңлаулар беркетмәсеннән өземтәләр бирүне гамәлгә ашырырга.

**Ачык тыңлаулар рәисе,**
**Лаеш Башкарма комитеты җитәкчесе ________________________ В.А. Арефьев**